
# Болыннарда икәү йөргән идек

*Самат Шакир сүзләре*




Бо-лын-нар - да и-кәү йөр-гән и - дек, жәй-ге ал-су тан-
нар ат-кан-да. Яшь - лек мә-хәб-бә-тем-не бел-де - реп яз -
rit.
ган и-дем си - нa хат-лар - да. Без ул чак-та кау-ша
rit.
molto rit.
ал-ма-дык, бәгъ-рем... Ни ө - чен? Ни ө-чен?
molto rit.




1981

Болыннарда икәү йөргән идек,
Җәйге алсу таңнар атканда.
Яшьлек мәхәббәтемне белдереп
Язган идем сиңа хатлар да.
Без ул чакта кауша алмадык, бәгърем...
Ни өчен? Ни өчен? Ни өчен?
Еллар узган саен онытылмадың,
Тәүге мәхәббәт гел хәтердә.
Зифа буең, кара күзләреңне
Күрәм кебек әле хәзер дә.
Без, сөеклем, бергә була алмадык...
Ни өчен? Ни өчен? Ни өчен?
Язлар килгән саен уйлыйм сине,
Йөзләремә чыга сагышлар.
Ялгыз каен җырлый үз телендә:
«Шулай була кайчак язмышлар».
Без, сөеклем, бергә була алмадык...
Ни өчен? Ни өчен? Ни өчен?